ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03 09 2024 г. № 938

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 31 июлендәге 603 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 75 статьясы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 31 июлендәге 603 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 пунктчасында «муниципаль заказны урнаштыру» сүзләреннән соң «Икътисад һәм сәнәгать идарәсе» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта:

«Тапшырырга» сүзләреннән соң «Беренче» сүзен өстәргә,

«Беляев Р.И.» сүзләрен «Мөхәммәтҗанов И.И.» сүзләренә алмаштырырга.»;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәдә (1 нче кушымта):

11 пунктның икенче абзацында «сәүдә һәм кулланучылар хезмәтләре күрсәтү бүлеге» сүзләрен «Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү идарәсенең эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «Төзелеш һәм архитектура идарәсе» сүзләрен «Шәһәр төзелеше сәясәте һәм архитектура идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә иҗтимагый туклануның стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм уздыру турындагы нигезләмәгә кушымтаны (2 нче кушымта) расланган карар белән яңа кушымтада бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Түбән Кама муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.И. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
«03» 09 2024 № 938

Кушымта
Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
территориясендә сезонлы объектларны
һәм җәмәгать туклануы объектларын
урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының һәм җәмәгать туклануы объектының сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукына шартнамәдә күрсәтелгән таләпләргә һәм типлаштырылган проектка туры килүе турында кабул итү комиссиясе акты

Түбән Кама шәһәре «__»_________20__ел.

Кабул итү комиссиясе составы:
Комиссия председателе:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары)

Комиссия членнары:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
( Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының җир һәм милек мөнәсәбәтләре идарәсе вәкиле)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Шәһәр төзелеше сәясәте һәм архитектура идарәсе вәкиле)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориаль иҗтимагый үзидарә советлары вәкиле)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү идарәсенең эшмәкәрлеккә ярдәм бүлеге вәкиле)

______________________________________________________________________
(сәүдә субъекты)

кабул итте:

1. Сәүдә субъекты белән

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(юридик зат яисә шәхси эшмәкәр күрсәтелә)

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты/җәмәгать туклануы объекты кабул итүгә тәкъдим ителде

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(төре)

______________________________________________________________________________

(алга таба - Объект) гамәлгә ашыру өчен

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(эшчәнлек төре, сатыла торган товарлар, күрсәтелә торган хезмәтләр төркеме)

адреслы ориентир буенча кишәрлектә___________ кв.м гомуми мәйданы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасы нигезендә:

______________________________________________________________________________

(Объектның урнашу урыны)

2. Эшләр түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырылды:

- сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын / җәмәгать туклануы объектын ______________________________ урнаштыру хокукына шартнамә;

- типлаштырылган (килештерелгән) проект

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(архитектура чишелешенең исеме, характеристикалары күрсәтелә)

3. Кабул итүгә тәкъдим ителгән Объект түбәндәге күрсәткечләргә ия:

а) Корылманың мәйданы - _________ кв.м.;

б) Корылманың киңлеге/озынлыгы - ________м.;

в) секцияләр саны (булган очракта) - _________бер.;

г) җәмәгать туклануы объекты өчен утырту урыннары саны________бер.;

д) объект башкарылган материал - ____________________________;

е) өстәмә күрсәткечләр: ________________________________________.

Ачыкланган хокук бозулар буенча кабул итү комиссиясе тәкъдимнәре:____________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

___________

4. Әлеге акт күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында күчемсез мөлкәт объекты сыйфатында объектка хокукны теркәү мөмкинлеген юкка чыгара.

Кабул итү комиссиясе карары:

Кабул итүгә тәкъдим ителгән Объект күрсәтелгән таләпләргә (туры килми) туры килә ________________________________________________

________________________________________________________________________,

(документ реквизитлары)

һәм эксплуатациягә әзер (әзер түгел).

Кабул итү комиссиясе Председателе:

___________________________________/___________________________________

(вазыйфасы.) (подпись) (Ф.И.О.)

5. Кабул итү комиссиясенең ачыкланган тәртип бозулар буенча тәкъдимнәр

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Кабул итү комиссиясе членнары:

____________________________________________/______________________________

____________________________________________/______________________________

____________________________________________/______________________________

____________________________________________/______________________________

Сәүдә субъекты:

____________________________________________/______________________________

Акт ике нөсхәдә төзелгән, берсе - сәүдә субъекты өчен, икенчесе - шәһәр җирлеге администрациясе өчен.